# HOMOGENEOUS PARTS OF THE SENTENCE IN TATAR LINGUISTICS: THE HISTORY OF STUDY

**Ramilya Kamilevna Sagdieva,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation.
ramsag777@rambler.ru.

The paper traces the history of studies of homogeneous parts of the sentence in the Tatar language from the first grammar books to modern linguistic research. The paper focuses on the devices, providing homogeneous base for parts of the sentence, the devices used to join them and their stylistic function. The article also focuses on the role of homogeneous parts, or clauses in creating a period in poetry and its functional and stylistic roles.

**Key words**: homogeneous parts, parts of a sentence, coordinating connection, intonation, linking word, meaning, period.

The homogeneous parts of a sentence are a syntactic unit, used to avoid iteration in a sentence. On the one hand, they make a sentence unextended, on the other hand, they make a sentence complete. Both coordinating and subordinative conjunctions are used to join homogeneous parts of a sentence. All homogeneous parts refer to the same part of the sentence and have the same connotation.

Tatar grammar defines homogeneous parts of a sentence in the following way: "The parts which refer to the same part of a sentence and have the same connotation are called homogeneous parts. Among the features, permanently characterizing homogeneous parts, are coordinating (copulative, adversative, and disjunctive) conjunctions, placed between them" [Tatar Grammar, p. 175].

Homogeneous parts were mentioned as early as in the first Tatar grammar books [Khalfin], [Ivanov], [Makhmudov]. Obviously, there existed no theoretic information, no definition and no term 'homogeneous parts' in these works. Clauses with homogeneous parts were provided as examples only when they exemplified the use of conjunctions: *Яшьләр уйныйлар, ир уртасы вә картко-ры кешеләр өйдә ашап–эчеп утыралар (The young people are playing, the middle-aged and old people are having a meal in the house)* [Makhmudov, p. 255]. Kayyum Nasyri's "Tatar Concise Grammar in Patterns", published in 1860, made a step forward in this direction. Homogeneous parts were considered not only in the Morphology, but also in Syntax. No explanation for homogeneous parts or coordinating conjunctions was given, of course. In this textbook, the author, by giving examples, proved that only the subject and the predicate could have homogeneous parts. He called homogeneous subjects "complex subjects", providing the following examples: *The father and the mother came. You and I are lazy. We, you, they drank.* (*Әтиһәмәникилде. Миндәсиндәялкау. Без, сез, аларэчдек*). And speaking about "complex predicates", the author meant homogeneous predicates:

Шикәр тәмле һәм ак, каты. Урам бик былчырак һәм тайгак. Син уйныйсың, көләсең, шаярасың, ялкауланасың, сабак укымыйсың (Sugar is sweet and white, hard. The road is so dirty and slippery. You are playing, laughing, having fun, being lazy, and neglecting your schoolwork) [Nasyri, p. 41].

First examples of punctuation used with homogeneous parts are found in Kayyum Nasyri's book. According to these examples, the author puts a comma between homogeneous parts connected by the intonation of enumeration, and no punctuation mark is used when they are linked by coordinating conjunctions (even in case of iteration).

Homogeneous parts were also considered to be a compound part of the sentence in Hadi Maksudi's textbook "Төрки нәхүе" ("Tatar Syntax") published in the beginning of the 20th century. The author paid special attention to the use of conjunctions [Maksudi, p. 25].

Galimzhan Ibragimov's "Татар нәхүе" ("Tatar Syntax") (1911) differed in content and structure, giving factual information from the previously published textbooks: homogeneous parts were described in syntactic terms, viewed not as compound parts of a sentence. G. Ibragimov did not use the term "homogeneous parts", he called the sentences with coordinating connection words "joint sentences (оешкан җөмлә)": "If there are more than one parts in a sentence, the sentence is called a joint sentence" [Ibragimov G., p. 27]. The

author wrote there could be at least two words with a coordinating connection, they link "уртак (common)" words, and such sentences could not be divided into parts.

Galimzhan Ibragimov's textbook "Татар нәхүе" contained first grammar rules on punctuation marks, used with homogeneous parts. According to the author, if there were only two words with coordinating connection in a "joint sentence", you put a comma between them. Homogeneous parts could be joined by such conjunctions as *ve, ham, da*. In fact, we could also use a comma or other "ярдәмлекләр (helpers)"– copulative conjunctions - between homogeneous parts if there were more than two of them, which was proved by an extract from GabdullaTukay's work: *You should study, stand up firmly, don't fall, don't fall, stand straight, sit up straight, sit well! (G. Tukay)* [ibid., p. 29].

G. Ibragimov stressed the importance of differentiating between homogeneous parts and repetition of words, not including word repetition in "joint sentences", but using the term *takrar* (repeat): "Hurt, hurt, hurt my soul...": this example, unlike the previous one, is not a joint sentence. These words may be repeated to explain the same meaning, or express and emphasize the same idea. Thus, repetition of words in order to emphasize the same meaning is called *takrar*" [ibid., p. 30].

Homogeneous parts were considered as a part of a sentence in M. Kurbangaliev and Kh. Badigyj's textbook "Ana tele нәхүе" ("Mother Tongue Syntax") (1919). The authors began with identifying three features typical of "joint sentences". According to them, firstly, principal and subordinate parts of the sentence could be similar, and secondly, all homogeneous parts in a sentence refer to the same word. Thirdly, "a joint sentence" or a sentence with homogeneous parts could be divided into several parts: "Every joint sentence can be divided into different sentences. For example, the sentence "*Кояш җиргә яктылык һәм җылылык бирә* (*The Sun gives light and warmth to the ground)"* can be divided into shorter sentences in this way: *"Кояш җиргә яктылык бирә. (The Sun gives light to the ground)". "Кояш җиргә җылылык бирә* (*The Sun gives warmth to the ground)*" [Kurbangaliev, Badig, pp. 39–40].

This textbook was the first to separately present homogeneous and non-homogeneous parts of the sentence. The authors underlined that the third condition was necessary to make the parts of the sentence homogeneous and proved it by giving examples: "*1) Бу бәйләмдә ак һәм ал чәчәкләр бар.* (*There are white and pink flowers in this bunch). 2) Бу бәйләмдә ал чәчәкләр бар. (There are pink flowers in this bunch).* If we say, "there are very nice white flowers in this bunch", the sentence will not be "a joint sentence", because it cannot be divided into two sentences. Any other flower cannot be called *very nice*. But only white flowers, which are in the bunch. The sentence "This summer I have lived in Kazan, Ufa, and Chistopol" is "a joint sentence". But the sentence "I have lived at 15 Tukay Street, in Kazan" is not "a joint sentence" [ibid., p. 40]. Even though the authors underlined that it was important not to confuse homogeneous and repeated parts, unlike G. Ibragimov, they believed homogeneous parts were linked by "connective words (*һәм, дә, да, янә, тагы, тагын, вә, мәгәр, ләкин, йә, әмма, йә-йә, яки, яисә*), adverbs (*бәлки, әвәл, соңрак, аннансоң, аныңартыннан*) and pronouns (*кайда-кайда, кайсы-кайсы*)". The scholars always exemplified their ideas with facts and attempted to prove that coordinating, disjunctive, and alternative conjunctions could be used with homogeneous parts: *Ул инде ашаган да, эчкән дә. Гали укымады, ә язды. Килүче Гали түгел, бәлки Вәлидер. Гали, аннансоң Әхмәт килде. Кунаклар килә башладылар: кайсыат белән, кайсы җәяү. Гали укымады, язды* (*He has already eaten and drunk. It's not Gali who is coming, but Vali. Gali came, and then Akhmet followed. The guests began to arrive: some on horseback, others on foot. Gali didn't read, but wrote)* [ibid., p. 41–42]. Even if such terms as 'intonation of enumeration or contrasting' were not mentioned, an idea was expressed that in the last example the words linking homogeneous parts could be omitted. For the first time, the idea about using a comma between homogeneous parts was suggested. At the same time, the authors defined clauses with coordinating connection as homogeneous parts.

In the textbook "Гамәли тел сабаклары (Practical Language Lessons)" (1925), this problem was discussed in the Part "Connecting Several Sentences" and the material of the previous book was repeated word for word [Гамәли тел сабаклары, p. 80–81].

Homogeneous parts were mentioned in the Part "Joint Sentences" in G. Alparov's book "Шәкли нигездә татар грамматикасы (Formal Tatar Grammar)" (1926) in the same way as it had been done in G. Ibragimov's book. The author gave examples of homogeneous subjects, predicates, attributes, and objects. The scholar highlighted the use of punctuation marks, intonation and noted that

the homogeneous parts in a sentence could be recognized by “the intonation of enumeration” and “a short pause” made between them in pronunciation, he also mentioned the use of a comma between them. Similar to G. Ibragimov and M. Kurbangaliev’s opinions, G. Alparov proved that homogeneous parts come from two or three joint sentences: “They are formed from several clauses joined into one sentence, when similar words are omitted and other words are combind. For example: if we don’t repeat the similar words of the sentences *I have eaten. I have drunk. I have gone to the school* and combine them, we get one joint sentence *I have eaten, drunk and gone to the school*” [Alparov, p. 155]. Thus, it was the time when first ideas on the stylistic role of homogeneous parts were expressed.

The term “homogeneous parts” was first used in Sh. Atnagulov and G. Alparov’s textbook for schools “Grammar. Syntax”(1934). These authors were the first to clarify the difference between connotations of homogeneous parts, based on coordinating conjunctions. They also studied non-homogeneous parts and called them “coordinating subordinate parts”: “coordinating subordinate parts can be attributes, objects and adverbs. Such conjunctions as *һәм, яки, ягъни* cannot be used with coordinating homogeneous parts. Consequently, to find out if the same form subordinate parts are equal parts or coordinating subordinate parts such conjunctions as *һич, яки* should be put between them” [Atnagulov, Alparov, p. 19].

The works published in the middle of the 20th century [Zakiev, 1958], [Khangildin], [Zakiev] suggested that all parts of the sentence could be homogeneous, that they could be linked by means of intonation and coordinating conjunctions, they also provided information about punctuation marks used with homogeneous parts and considered general words related to homogeneous parts: “General words can come after or before homogeneous parts. General words join the similar parts together and they depend on the subordinating word. General words characterise subordinating words in the same way as homogeneous parts do. Pronouns and the words replacing pronouns, such as *гадәттә, һәммәседә, барысыда, бөтенесе, һичнәрсә, һичкем, һичбере,* are usually general words” [Zakiev, 1958, p. 175–176].

S. M. Ibragimov focused on the stylistic use of homogeneous parts. He described the features of use of homogeneous parts in the chapter “The Stylistic Role of the Homogeneous Parts in a Sentence” in his book “Syntax Stylistics”. According to S. M. Ibragimov, “certain authors employ symmetrical use of homogeneous parts and produce a hasteless, steady tone of narration in their works” [Ibragimov S., p. 83]. The scholar also noted the parallel use of homogeneous parts in the works of certain writers and journalists: “In this case, two parts, coming close to each other, are joined by the same conjunction, and they are connected by coordinating intonation. To draw attention to each of the homogeneous parts <....> each of them can be used with the coordinator” [ibid.]. By using the conjunction *һәм* before the last of the enumerated homogeneous parts, we mean to say that the enumeration is coming to an end and finish it. S. M. Ibragimov analyzed the use of homogeneous parts through different styles. The scholar wrote: “general words before homogeneous parts are used in a publicistic style, and their use after homogeneous parts is characteristic of a conversational style” [ibid., p. 84].

In the book, special attention was paid to the synonymy of coordinators of homogeneous parts. The scholar focused on such issues as the use of the conjunctions *я* and *яисә* in the same sentence, alternation of the conjunctions *һәм, вә, да* and other issues. Coordinators of homogeneous parts, performing different roles, should be used with great care. The book provides examples of communication failures in case of the wrong use of these forms.

F. S. Khakimzyanov and M. M. Shakurova’s major work “Modern Tatar Language: Punctuation” was published in 2003. Traditionally, academic works explore a comma, semicolon and dash used with homogeneous parts. This book contains linguistic material on a period, question mark, ellipsis and colon. The authors substantiated their ideas with interesting examples [Khakimzyanov, Shakurova].

In his article “Syntactic Functions of Homogeneous Parts and General Word” (2003), F. G. Gallamov identified several types of homogeneous parts and general words based on the use of the conjunctions *да / дә / та / тә*. The article also focuses on explanatory relations between general words and homogeneous parts, and provides numerous examples related to the issue. The author noted that homogeneous parts and general words could be an attribute and attributer. F. G. Gallamov came to the conclusion that “if there are general words before and after, they make a compound sentence” [Gallamov, p. 46]. However, we cannot say it is always true.

Academician M. Z. Zakiev also conducted research into homogeneous parts. In his university textbook on syntax, the scholar underlined that all parts of the sentence –principle, secondary and modal – could be homogeneous. He clarified the role of coordinating conjunctions in relationships between homogeneous parts, taking into account the ways of linking [Zakiev, 2005, pp. 133–135].

The latest major work on homogeneous parts is L. R. Mirsaipova's Ph. D. thesis "The Homogeneous Parts and General Words in Modern Tatar Literary Language" (2010). The author examines morphological and syntactic characteristics of homogeneous parts and general words in the modern Tatar literary language [Mirsaipova].

Homogeneous parts of the sentence are also discussed in Methodology of Teaching Tatar. The scholars approve of the methods used in teaching this topic [Improving the Effectiveness of Teaching the Tatar Language to Foreign Learners], [On the Origin, Phonetic Variants, Semantic and Stylistic Peculiarities of the Use of the Affix *-lar* in Turkic Languages] [Husnutdinov, Sagdieva].

The term *тезем* (chain, period) referring to homogeneous parts is another focus of a linguistic research connected with the stylistic aspect of the use of homogeneous parts. "Simple or compound sentences which are extended because of many homogeneous parts or clauses are called *тезем* (chain, period)" [Zakiev, 2005, p. 353]. 'Tezem' is understood as a complete text. The enumeration of homogeneous parts or clauses is more typical of poetry, however, sometimes it is used in prose.

As a rule, 'tezem' contains an enumeration and main parts. It can have a falling, rising and rising-falling tone, depending on the position of the enumeration and main parts, and intonation peculiarities. The falling 'tezem' is used in F. Yarullin's poem "Will Burn for Long", because the enumeration is placed at the beginning of the sentence and the main part is at the end:

Кеше бит ул бер учак:
Утынын сала торсаң,
Көлләрен ала торсаң,
Бераз кузгатып куйсаң,
Утын уятып куйсаң,
Давылдан саклый алсаң,
Явымнан каплый алсаң,
Сүнгәндә өргәләсәң,
Яңа көч биргәләсәң,
Күмерен таратмасаң,
Урынын яңартмасаң,
Таш белән бастырмасаң,
Боз белән катырмасаң,
Ялкыннарын үрләтсәң,
Күмерләрен дөрләтсәң –
Бу учак
Озак-озак яначак [Yarullin, 2003, p. 264]. –

A person is a bonfire:
If you add firewood to it,
And take the ash away,
If you move it a little,
And keep the fire up,
If you can keep it from the storm,
And cover it from the rain,
If you blow it up when it's going out,
And inspire it with a new life,
If you don't waste its coal,
And don't remove it,
If you don't cover it with a stone,
And don't freeze it,
If you kindle it into flames,
And keep the fire –
This bonfire
Will burn for a long time.

There may be different connections between the parts of tezem: of subject, predicate, time, attribute, place, as well as adverbial, conditional, final, concessive, qualifying, 'tezem' of address and coordination. Both homogeneous parts and homogeneous clauses can be used in the enumeration.

Homogeneous parts, as well as 'tezems', have been used in the Tatar language since ancient times. Good examples of use can be found in the works of ancient and modern literature.

Stylistic aspects of use of the homogeneous parts in a sentence have become a focus of linguistic research in recent years. In the research of the style of a poet or writer homogeneous parts are analyzed as a device of imagery [Nurieva], [Practical Aspects of Comparative Research Based on the Russian and Tatar Languages: 19th–21st centuries]. All these make it possible to improve the modern Tatar literary language and maintain language norms.

Today the theory of homogeneous parts in Tatar Linguistics is very well systematized. Academic books on syntax and textbooks for universities and secondary schools give similar definitions, and there is no discrepancy between scholars concerning linking devices joining homogeneous parts. Nowadays, the most important problem the Tatar Linguistics is facing is functional aspects of homogeneous parts.

**References**

Alparov, G. (1926). *Shakli Nigezda Tatar Grammatikasy* [Formal Tatar Grammar]. 164 p. Kazan. (In Tatar)

Atnagulov, S., Alparov G. (1934). *Grammatika. Sintaksis* [Grammar. Syntax]: Urta maktaplare ochen dareslek. 142 p. Kazan. (In Tatar)

Fattahova, R. F., Sagdieva, R. K., Aydarova, S. H., Giniyatullina, L. M. (2016). *On the Origin, Phonetic Variants, Semantic and Stylistic Peculiarities of the Use of the Affix-Lar in the Turkic Languages*. Man in India. No. 96 (10). Pp. 3529–3539. (In English)

Gallamov, F. G. (2003). *Tindash kisaklarnen ham gomumilashteruche suzlarnen sintaksik vazyifalary* [Syntactic Functions of the Similar Parts and the General Word]. Pp. 41–46. Millimadaniyat. Kazan. (In Tatar)

*Gamali Tel Sabaklary* (1925). [Practical Language Lessons]. 99 p. Kazan. (In Tatar)

Husnutdinov, D. H., Yusupova, Z. F., Shakurova, M. M., Yusupov, A. F., Mirzagitov, R. H. (2016). *Practical aspect of comparative research on the material of the Russian and Tatar Languages: XIX–XXI centuries.*Journal of Language and Literature. No.7 (2). Pp. 191–194. (In English)

Husnutdinov, Damir H.; Sagdieva, Ramilya, K. *Using Computer Technologies in Teaching Process.*Turkish online journal of design art and communication. No.6. Pp. 2369–2375. (In English)

Ibragimov, G. (1919). *Tatar Nakhue* [Tatar Syntax]. 52 p. Kazan: “Omet” publishing house. (In Tatar)

Ibragimov, S. M. (1989). *Sintaksik Sinonimnar* [Syntactic Synonims]. 150 p. Kazan: KSU publishing house. (In Tatar)

Ivanov, M. (1842). *Tatarskaya Grammatika* [Tatar Grammar]. 342 p. Kazan: KSU publishing house. (In Russian)

Khalfin, I. (1809). *Azbuka I Grammatika Tatarskogo Yazyka s Obstoyatelnym Opisaniem Bukv I Skladov* [Tatar Alphabet and Grammar with Compulsive Description of Letters and Syllables]. 107 p. Kazan: KSU publishing house. (In Russian)

Khangildin, V. N. (1959). *Tatar Tele Grammatikasy (Morfologiyaham sintaksis)* [Tatar Grammar (Morphology and Syntax)]. 642 p. Kazan: Tatar publishing house. (In Tatar)

Khakimzyanov, F. S., Shakurova M. M. (2003). *Khazergetatartele: Punktuatsiya* [Modern Tatar Language: Punctuation]. 168 p. Kazan: TSHI. (In Tatar)

Korbangaliev, M. (1919). Badig, Kh. *Ana Tele Nakhue* [Native Language Syntax]. 100 p. Kazan: “Milliyat” publishing house. (In Tatar)

Makhmudov, M. (1857). *PrakticheskoeRukovodstvo k IzucheniyuTatarskogoYazyka*[Practical Manual on Learning Tatar]. 255 p. Kazan: I. Dubrovina publishing house. (In Russian)

Maksudi, Kh. (1910). *Torki Nakhue* [Turkic Syntax]. 50 p. Kazan: Kharitonov publishing house. (In Tatar)

Mirsiapova, L. R. (2010). *Odnorodnye Chlenyi Obobshchaiushchie Slova v Sovremennom Tatarskom Literaturnom Iazyke* [The Similar Parts and the General Words in Modern Tatar Literary Language: Ph.D. Thesis Abstract]. 20 p. Kazan. (In Russian)

Nasyri, K. (1860). *Kratkaia Tatarskaya Grammatika, Izlozhennaia v Primerakh* [Tatar Brief Grammar in Samples]. 79 p. Kazan. (In Russian)

Nurieva, F. Sh. (2014). *Literary Language of the Golden Horde: Norms and Variations*. Life Science Journal, No. 10 (11). Pp. 713–717. (In English)

*Tatar Grammatikasy* (1999) [Tatar Grammar]. In 3 volumes. V. III. 512 p.: Insan, Kazan: Fiker. (In Tatar)

Yarullin, F. G. (2003). *Kүңel yaktysy. Shigyr'lər, poema*. [The Light of the Soul. Verses, a Poem]. 384 p. Казан: Татар. кит. нәшр. (In Tatar)

Yusupov, R. A., Aydarova S. H., Sagdieva R. K., Harisova, G. F. (2015). *Improving Efficiency of Teaching the Tatar Language to a Foreign Audience.* International Education Studies. No.8 (5). Pp. 158–164. (In English)

Zakiev, M. Z. (1963). *Sintaksicheskiy Stori Tatarskogo Iazyka* [Syntactic Formation of Tatar]. 464 p. Kazan: KSU publishing house. (In Russian)

Zakiev, M. Z. (1958). *Khazerge Tatar Adəbi Tele: Sintaksis* [Modern Tatar Literary Language: Syntax]. 244 p. Kazan: KSU publishing house. (In Tatar)

Zakiev, M. Z. (2005). *Tatar Sintaksisy* [Tatar Syntax]: Yugary uku yortlary ochen d-lek. 399 p. Kazan: Magarif. (In Tatar)


# ТАТАР ТЕЛЕ БЕЛЕМЕНДӘ ТИҢДӘШ КИСӘКЛӘРНЕ ӨЙРӘНҮ ТАРИХЫННАН


**Рамилә Камил кызы Сәгъдиева,**

Казан федераль университеты,

Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,

ramsag777@rambler.ru.



Мәкаләдә татар телендә тиңдәш кисәкләрнең өйрәнелеше турында сүз бара. Беренче грамматикалардан алып бүгенге чорга караган фәнни хезмәтләрдә әлеге теманың чагылыш дәрәҗәсе ачыклана. Теге яки бу җөмлә кисәгенең тиңдәшләнеп килү ысулларына, аларны бәйли торган чараларның кулланылышына, стилистик алым буларак чагылышына да игътибар

бирелә. Шигъри әсәрләрдәге тиңдәш кисәкләрнең яисә тиңдәш җөмләләрнең тезем оештырудагы роле, теземнең функциональ-стилистик функциясе дә ассызыклана.

**Төп төшенчәләр:** тиңдәш кисәкләр, җөмлә кисәкләре, тезүле бәйләнеш, интонация, теркәгеч, мәгънә, тезем.

Тиңдәш кисәкләр – җөмләдәге кабатлаулардан коткара торган синтаксик берәмлек. Ул, бер яктан, җөмләне җыйнакландырса, икенче яктан, аны тулыландыра да. Тиңдәш кисәкләр хасил булсын өчен, җөмләдә ияртүле бәйләнешнең дә, тезүле бәйләнешнең дә булуы шарт. Тиңдәш кисәкләрнең барысы да бер генә җөмлә кисәгенә ияреп килә һәм аның белән бер үк мәгънә мөнәсәбәтендә тора.

Татар грамматикасында тиңдәш кисәкләргә түбәндәге билгеләмә бирелә: «Нинди дә булса бер кисәккә караган һәм шул кисәккә карата бер үк мәгънә мөнәсәбәтендә торган кисәкләр тиңдәш кисәкләр дип аталалар. Тиңдәш кисәкләрнең кагыйдә итеп алырлык һәрвакыт була торган үзенчәлекләре шунда: алар арасында тезүче (җыючы, каршылык, бүлгәләүче) теркәгечләр кулланыла яисә анда ул теркәгечләрне куярга мөмкин була» [Татар грамматикасы, б. 175].

Тиңдәш кисәкләр татар теленең беренче грамматикаларында ук телгә алына башлый [Хальфин], [Иванов], [Махмудов]. Әлбәттә, әлеге хезмәтләрдә теоретик мәгълүмат, билгеләмә һәм, гомумән, тиңдәш кисәк дигән термин юк. Тиңдәш кисәкле җөмләләр бары тик теркәгечләрне өйрәнгәндә генә мисал итеп китерелә: *Яшьләр уйныйлар, ируртасы вә карт-коры кешеләр өйдә ашап-эчеп утыралар* [Махмудов, б. 255]. Каюм Насыйриның 1860 елда басылган «Краткая татарская грамматика, изложенная в примерах» хезмәтендә берникадәр алга китеш сизелә. Тиңдәш кисәкләр морфология бүлегендә генә түгел, ә синтаксис эчендә дә карала. Әлбәттә, Каюм Насыйри да тиңдәш кисәкләр яки тезүле бәйләнеш хакында аңлатма бирми. Үз дәреслегендә автор бары тик ия белән хәбәрнең генә тиңдәшләнеп килә алуын мисаллар ярдәмендә дәлилли. Тиңдәш ияләргә *Әти һәм әни килде. Мин дә син дә ялкау. Без, сез, алар эчдек* кебек мисаллар китереп, аларны «катлаулы ияләр» дип атый. Ә «катлаулы хәбәрләр» дигәндә, автор тиңдәш хәбәрләрне күз алдында тоткан:

> Шикәр тәмле һәм ак, каты. Урам бик былчырак һәм тайгак. Син уйныйсың, көләсең, шаярасың, ялкауланасың, сабак укымыйсың [Насыйри, б. 41].

К. Насыйриның әлеге хезмәтендә тиңдәш кисәкләр пунктуациясе белән бәйле беренче үрнәкләрне дә очратырга мөмкин. Мисаллардан күренгәнчә, автор санау интонациясе аша бәйләнгән тиңдәш кисәкләр арасына өтер куйса, җыючы теркәгечләр ярдәмендә тезелеп киткән очракта (хәтта кабатланып килсәләр дә) бернинди дә тыныш билгесе куймау яклы.

Һади Максудиның XX йөз башында нәшер ителгән «Төрки нәхүе» дәреслегендә дә тиңдәш кисәкләр җөмләнең кушма кисәге итеп карала, һәм автор төп игътибарын бары тик теркәгечләргә генә юнәлтә [Максуди, б. 25].

Галимҗан Ибраһимовның «Татар нәхүе» (1911) хезмәте эчтәлеге һәм төзелеше ягыннан да, фактик материалларның бирелеше белән дә аңа кадәр басылган дәреслекләрдән аерылып тора. Анда тиңдәш кисәкләр тулысынча синтаксис эчендә карала, һәм алар, җөмләнең кушма кисәге буларак түгел, ә билгеле бер җөмлә эчендә тикшерелә, анализлана башлый. Г. Ибраһимов та тиңдәш кисәк дигән терминны кулланмый, бары тик үзара тезүле бәйләнештәге сүзләре булган җөмләләрне генә «оешкан җөмлә» дип аерып бирә: «Җөмләнең кисәкләреннән берсе бердән артык булса, ул җөмләне „оешкан җөмлә“ дип атыйлар» [Ибраһимов Г., б. 27]. Автор җөмләдә тезүле бәйләнештә килгән сүзләрнең кимендә икәү булулары, аларның бер үк төрле формада «уртак» сүзгә ияреп килүләре, әлеге җөмләнең аерым компонентларга таркала алмавы хакында бәян итә.

Г. Ибраһимовның «Татар нәхүе» дәреслегендә тиңдәш кисәкләргә караган тыныш билгеләренә бәйле беренче кагыйдәләр урын ала. Автор фикеренчә, «оешкан җөмләнең» тезүле бәйләнештәге сүзләре «ике генә булса», алар арасына өтер куела. Хезмәттә тиңдәш кисәкләрнең вә, һәм, да кебек теркәгечләр ярдәмендә бәйләнеп килә алулары да искәртелә. Тиңдәш кисәкләр икедән артыграк булганда, алар арасына өтер яисә «ярдәмлекләр» – җыючы теркәгечләр дә куярга мөмкин булганлыгы Габдулла Тукай әсәреннән алынган өзек ярдәмендә дәлилләнә: *Өйрән син, арт аягың берлә тор, аума, аума, туп туры тор, төз утыр, яхшы утыр! (Г.Тукай)* [Шунда ук, б. 29].

Г. Ибраһимов тиңдәш кисәкләр һәм сүзнең кабатлану күренешен аерырга кирәклеген ассызыклый һәм бер үк сүзнең берничә тапкыр кабатланып килүен «оешкан җөмлә»ләр рәтенә кертми, ә тәкрар термины белән бирә: «Сызла, сызла, сызла күңлем... Ләкин болар, моңа карап, оешкан җөмлә булмыйлар. Бәлки берүк мәгънәне, берүк фикерне артык дәрәҗәгә күтәрүне аңлату өчен китерелгәннәр. Шул рәвешчә: бер сүзнең, берүк мәгънәне куәтләү өчен, берничә тапкыр кулланылуын „тәкрар“ дип атыйлар» [Шунда ук, б. 30].

М. Корбангалиев һәм Х. Бәдигыйләрнең «Ана теле нәхүе» (1919) дәреслегендә тиңдәш кисәкләр җөмлә эчендә тикшерелә. Авторлар мәсьәләне «оешма җөмләләргә» хас өч үзенчәлек белән таныштырудан башлыйлар. Алар фикеренчә, беренчедән, җөмләдә баш һәм иярчен кисәкләр тиңдәшләнеп килә алалар. Икенчедән, җөмләдәге тиңдәш кисәкләр һәрберсе бары тик бер генә сүзгә ияреп килергә тиеш. Өченчедән, тиңдәш кисәкле, ягъни «оешма җөмлә» аерым компонентларга таркала ала: «Һәрбер оешма җөмлә аерым җөмләләргә бүленергә тиеш. Мәсәлән: Кояш җиргә яктылык һәм җылылык бирә дигән җөмләне ошбу рәвешчә аерым җөмләләргә бүлергә мөмкин: Кояш җиргә яктылык бирә. Кояш җиргә җылылык бирә» [Корбангалиев, Бәдигъ, б. 39–40].

Дәреслектә беренче тапкыр җөмләдәге тиңдәш һәм тиңдәш булмаган кисәкләр аерып күрсәтелә. Авторлар җөмлә кисәкләренең тиңдәшләнүе өчен югарыда ассызыкланган өченче шарт булу мөһимлеген искәртәләр һәм мисаллар белән раслыйлар: «1) Бу бәйләмдә ак һәм ал чәчәкләр бар. 2) Бу бәйләмдә ал чәчәкләр бар. Әгәр бу бәйләмдә бик матур ак чәчәкләр бар дисәк бу җөмлә „оешма җөмлә“ булмый. Чөнки моны ике җөмләгә аерып булмый. Монда бик матур дип әллә нинди бүтән чәчәкләр әйтелмәгән. Бәлки бу бәйләмдә булган ак чәчәкләр генә әйтелгән. Мин быел җәй Казанда да, Уфада да, Чистайда да тордым җөмләсе бер „оешма җөмлә“ була. Әмма Мин Казанда Тукай урамында 15 нче номерлы йортта тордым җөмләсе оешма җөмлә була алмый» [Шунда ук, б. 40]. Тиңдәш кисәкләр белән кабатланган кисәкләрне бутамаска кирәклеген ассызыкласалар да, Г. Ибраһимовтан аермалы буларак, алар тиңдәш кисәкләр арасындагы бәйләнешне «теркәгеч сүзләр (һәм, дә, да, янә, тагы, тагын, вә, мәгәр, ләкин, йә, әмма, йә-йә, яки, яисә), хәл сүзләре (бәлки, әвәл, соңрак, аннан соң, аның артыннан) һәм алмашлыклар (кайда-кайда, кайсы-кайсы)» белдерүен билгелиләр. Галимнәр үз фикерләрен фактик мисаллар белән һәрдаим дәлилләп баралар һәм тиңдәш кисәкләр арасында җыючы, бүлүче, каршы куючы теркәгечләрнең кулланыла алуларын исбатларга омтылалар: *Ул инде ашаган да, эчкән дә. Гали укымады, ә язды. Килүче Гали түгел, бәлки Вәлидер. Гали, аннан соң Әхмәт килде. Кунаклар килә башладылар: кайсы ат белән, кайсы җәяү. Гали укымады, язды* [Шунда ук, б. 41–42]. Санау яисә каршы кую интонациясе дигән термин кулланылмаса да, соңгы мисалда тиңдәш кисәкләрне бәйли торган чараларның төшеп калу ихтималы булуы турындагы фикер чагыла. Тиңдәш кисәкләр арасында өтернең куелу-куелмау очраклары хакында да башлангыч һәм дөрес фикерләр әйтелә. Шул ук вакытта авторларның тиңдәш кисәкләр эченә тезүле бәйләнештәге җөмләләрне дә кертеп караганлыгы ачыклана.

«Гамәли тел сабаклары» (1925) дәреслегендә әлеге тема «Берничә җөмләне бергә оештыру» дип аталган бүлектә өйрәнелә һәм алдагы китапта бирелгән мәгълүматлар сүзгә-сүз кабатлана дияргә мөмкин [Гамәли тел сабаклары, б. 80–81].

Г. Алпаровның «Шәкли нигездә татар грамматикасы» (1926) хезмәтендә тиңдәш кисәкләр Г. Ибраһимовтагыча «оешкан җөмләләр» бүлегендә урын ала. Автор тиңдәш ияләргә, хәбәрләргә, аергыч һәм тәмамлыкларга мисаллар китерә. Галим, тыныш билгеләреннән тыш, интонациягә дә игътибар итә һәм җөмләдәге тиңдәш кисәкләрне «санап бирү тавышы белән әйтелүеннән дә» аерып булуына басым ясый, алар арасында «кечкенә бер тыныш (пауза)» ясалуын, өтер куелуын да искәртә. Г. Ибраһимов һәм М. Корбангалиев фикерләренә кушылып, Г. Алпаров тиңдәш кисәкләрнең ике яки өч җөмләнең кушылуы нәтиҗәсендә барлыкка килүен раслый: «Оешкан җөмлә төбендә берничә җөмләдән гыйбарәт булып, аларның берүк уртак сүзләрен ташлап, бер ничәсен бергә оештырып бер җөмлә итеп төзелгән була. Мәсәлән: Мин ашадым. Мин эчтем. Мин мәктәпкә киттем дигән өч җөмләнең уртак сүзләрен тәкрарламыйча, бергә кушсак, Мин ашадым, эчтем дә мәктәпкә киттем дигән бер оешкан җөмлә килеп чыга» [Алпаров, б. 155]. Димәк, бу чорда ук тиңдәш кисәкләрнең стилистик вазыйфалары турында башлангыч фикерләр әйтелгән дияргә нигез бар.

«Тиңдәш кисәкләр» дигән термин беренче тапкыр Ш. Атнагулов белән Г. Алпаровның урта мәктәпләр өчен «Грамматика. Синтаксис» (1934) дәреслегендә кулланылган. Авторлар, беренчеләрдән булып, тезүче теркәгечләр нигезендә, тиңдәш кисәкләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләрен ачыкларга омтылалар һәм, тиңдәш түгел кисәкләргә дә игътибар итеп, аларны «тезмә иярчен кисәкләр» дип атыйлар: «Тезмә иярчен кисәкләр аергыч булырга да, тәмамлык яки хәл булырга да мөмкин. Тезмә иярченнәр арасында һәм, яки, ягъни теркәгечләре килә алмыйлар. Шуңа күрә бер формадагы иярчен кисәкләрнең, тиң кисәкләрме, тезмә иярченнәрме икәнен белү өчен, аларның арасына һич, яки теркәгечләре куеп карарга кирәк була» [Атнагулов, Алпаров, б. 19].

XX гасыр урталарындагы хезмәтләрдә барлык җөмлә кисәкләренең тиңдәшләнеп килә алуы, алар арасындагы бәйләнешнең интонация һәм тезүче теркәгечләр ярдәмендә тормышка ашырылуы, тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре турында мәгълүматлар китерелә [Зәкиев, 1958], [Хангилдин], [Закиев]. Аларда тиңдәш кисәкләр белән бәйле булган гомумиләштерүче сүзләргә дә игътибар бирелә: «Җөмләнең тиңдәш кисәкләреннән соң яки алардан алда гомумиләштерүче сүзләр булырга мөмкин. Гомумиләштерүче сүзләр тиңдәш кисәкләрнең барысын бергә җыеп, гомумиләштереп әйтәләр, һәм алар тиңдәш кисәкләрне иярттүче сүзгә буйсыналар. Тиңдәш кисәкләр иярттүче сүзне кайсы яктан характерласалар, гомумиләштерүче сүз дә иярттүче кисәкне шул яктан ук характерлый. Гомумиләштерүче сүзләр булып, гадәттә һәммәсе дә, барысы да, бөтенесе, һичнәрсә, һичкем, һичбере кебек алмашлыклар һәм алмашлык урынындагы сүзләр йөриләр» [Зәкиев, 1958, б. 175–176].

С. М. Ибраһимов тиңдәш кисәкләрнең стилистик кулланылышына игътибар итә. Ул «Синтаксик стилистика» хезмәтенең «Җөмләдә тиңдәш кисәкләрнең стилистик роле» бүлегендә тиңдәш кисәкләрнең кулланылу үзенчәлекләренә туктала. С. М. Ибраһимов фикеренчә, «кайбер язучылар, тиңдәш кисәкләрнең симметрияле кулланылышына игътибар биреп, үз әсәрләрендә салмак кына ага торган, киң сулышлы язу алымы барлыкка китерәләр» [Ибраһимов С., б. 83]. Язучы һәм журналистларның тиңдәш кисәкләрне парлап кулланулары да галим игътибарыннан читтә калмый: «Бу очракта бер-берсенә якын төрләрнең икесе бер теркәгеч белән берләштерелә дә, алар тагын тезү интонациясе аша тиңдәшләнеп киләләр. Тиңдәш кисәкләргә аеруча басым ясап әйтергә кирәк булганда, сөйләмнең тәэсир көчен арттыру максатыннан, аларның һәркайсы бер үк бәйләүче чараның кабатлануы белән килергә дә мөмкин» [Шунда ук]. Саналып киткән тиңдәш кисәкләрнең соңгысы алдыннан һәм теркәгечен куллану санауның тәмамлануын белдерә, шулай итеп тиңдәш кисәкләрнең тезмәсе чикләнә. С. М. Ибраһимов тиңдәш кисәкләрнең кулланылышын төрле стильләр мисалында да анализлый. Мәсәлән, «гомумиләштерүче сүзләрнең алдан килүе язма стильгә, ә ахырдан килүе сөйләм теле стиленә хас», – дип яза автор [Шунда ук, б. 84].

Хезмәттә тиңдәш кисәкләрне бәйли торган чараларның синонимлыгына аерым урын бирелә. Тиңдәш кисәкләрне санап китү генә түгел, ә аларны бәйли торган чараларның бирелешенә дә аерым игътибар итү таләп ителә. Мәсәлән, я һәм яисә формаларын бер җөмлә эчендә файдалану, һәм, вә, да кебек теркәгечләрне чиратлаштыру һ. б. шундый мәсьәләләргә галим аерым басым ясый. Авторны тиңдәш кисәкләрне бәйләүче чараларның төрле функцияләрдә кулланылулары борчый. Ул әлеге формаларның сөйләмне бозган очракларын мисаллар ярдәмендә исбатлап бирә.

2003 елда Ф. С. Хәкимҗанов һәм М. М. Шәкүроваларның «Хәзерге татар теле. Пунктуация» дигән зур хезмәте басыла. Гадәттә, фәнни хезмәтләрдә тиңдәш кисәкләр янында өтер, нокталы өтер һәм сызык куелу очраклары ассызыкланып барса, әлеге хезмәттә исә тиңдәш кисәкләр белән бәйле нокта, сорау, күпнокта һәм ике нокта куелу очракларына да басым ясала. Авторлар шактый кызыклы һәм уйландыргыч фактик мисаллар ярдәмендә үз фикерләрен дәлилләп баралар [Хәкимҗанов, Шәкүрова].

Ф. Г. Галләмов «Тиңдәш кисәкләрнең һәм гомумиләштерүче сүзләрнең синтаксик вазыйфалары» (2003) мәкаләсендә тиңдәш кисәкләр һәм гомумиләштерүче сүзләр янында да / дә / та / тә теркәгечләренең булу-булмавына карап, аларның берничә төрен аерып чыгара. Мәкаләдә шулай ук гомумиләштерүче сүз белән тиңдәш кисәкләр арасында аныклаулы мөнәсәбәт булуы искәртелә, һәм аның төрле очраклары күпләгән мисаллар ярдәмендә дәлилләнә. Автор тиңдәш кисәкләр белән

гомумиләштерүче сүзләрнең аергыч белән аерылмыш вазыйфасында килүләрен дә ассызыклап үтә. Ф. Г. Галләмов «Гомумиләштерүче сүзләр алдан да, арттан да килсәләр, кушма җөмлә хасыйл була» дигән нәтиҗә ясый [Галләмов, б. 46]. Әмма бар очраклар да бу кагыйдәгә туры килә дип әйтеп булмый.

Академик М. З. Зәкиев тә үз хезмәтләрендә тиңдәш кисәкләргә караган мәгълүматларны тулыландырып тора. Югары уку йортлары өчен синтаксис дәреслегендә автор барлык җөмлә кисәкләренең – баш, иярчен һәм модаль кисәкләрнең дә тиңдәшләнеп килә алуларын ассызыклый. Галим, тезүче теркәгечләргә бәйле, тиңдәш кисәкләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләрен ачыклап бирә, аларның ярашу мәсьәләсенә, ягъни бер үк формада яисә төрле формаларда да кулланыла ала торган очракларга басым ясый [Зәкиев, 2005, б. 133–135].

Тиңдәш кисәкләр белән бәйле соңгы зур хезмәт – Л. Р. Мирсиапованың «Хәзерге татар әдәби телендә тиңдәш кисәкләр һәм гомумиләштерүче сүзләр» (2010) кандидатлык диссертациясе. Автор анда хәзерге татар әдәби телендәге тиңдәш кисәкләрнең һәм гомумиләштерүче сүзләрнең морфологик үзенчәлекләрен, синтаксик функцияләрен тикшерә [Мирсиапова].

Җөмләнең тиңдәш кисәкләренә татар телен уку-укыту методикасы кысаларында игътибар ителә. Галимнәр әлеге теманы аңлату методикасының кулай икәнлеген таныйлар [Improving efficiency of teaching the Tatar language to a foreign audience], [On the origin, phonetic variants, semantic and stylistic peculiarities of the use of the affix-lar in the Turkic languages], [Husnutdinov, Sagdieva].

Тел белемендә тиңдәш кисәкләргә бәйле тезем дигән төшенчә дә бик актуаль. Ул нәкъ менә тиңдәш кисәкләрнең стилистик кулланылышы белән бәйле. «Тиңдәш кисәкләре яки тиңдәш җөмләләре күп булу аркасында, бик нык җәенкеләнгән гади яки кушма җөмләгә тезем диләр» [Зәкиев, 2005, б. 353]. Тезем барлык яктан да бик нык оешкан текст буларак аңлатыла. Тиңдәш кисәкләрне яисә тиңдәш җөмләләрне тезеп китү, иң беренче чиратта, шигъри әсәрләргә хас, сирәк кенә булса да проза әсәрләрендә дә очратырга мөмкин.

Гадәттә, теземнең санау һәм төп бүлеге аерылып тора. Санау һәм төп бүлекләрнең урнашу тәртибе, интонация үзенчәлекләре белән бәйле, тезем төшмә, күтәрелмә һәм катнаш төрләргә бүленә. Ф. Ярулинның «Озак-озак яначак» шигырендә төшмә тезем файдаланыла, чөнки иң элек санау бүлеге, аннары төп бүлек урын ала:

Кеше бит ул бер учак:
Утынын сала торсаң,
Көлләрен ала торсаң,
Бераз кузгатып куйсаң,
Утын уятып куйсаң,
Давылдан саклый алсаң,
Явымнан каплый алсаң,
Сүнгәндә өргәләсәң,
Яңа көч биргәләсәң,
Күмерен таратмасаң,
Урынын яңартмасаң,
Таш белән бастырмасаң,
Боз белән катырмасаң,
Ялкыннарын үрләтсәң,
Күмерләрен дөрләтсәң –
Бу учак
Озак-озак яначак [Яруллин, 2003, б. 264].

Теземнең бүлекләре арасында төрле мәгънә мөнәсәбәтләре урнаша. Шул яктан ия тезем, хәбәр тезем, вакыт тезем, аергыч тезем, вакыт тезем, урын тезем, рәвеш тезем, сәбәп тезем, максат тезем, шарт тезем, кире тезем, аныклагыч тезем, эндәшле тезем, тезүле тезем кебек төркемнәр аерыла. Бу очракта санау бүлегендә тиңдәш кисәкләр дә, тиңдәш җөмләләр дә кулланылырга мөмкин.

Тиңдәш кисәкләр, шул исәптән, тезем дә татар телендә элек-электән үк кулланылган. Бик борынгы язмалардан алып хәзерге әдәби әсәрләрдә аларның матур үрнәкләрен очратырга мөмкин.

Соңгы елларда җөмләдәге тиңдәш кисәкләрнең стилистик кулланылышына да зур игътибар бирелә. Теге яки бу шагыйрьнең, язучының тел-стиль үзенчәлекләрен анализлаганда да, әсәрләрдәге тиңдәш кисәкләрнең нинди формада файдалануы, образлылык, сурәтләү чарасы буларак мөһим роль уйнаганлыгы ассызыклана [Nurieva], [Practical aspect of comparative research on the material of the Russian and Tatar Languages: XIX–XXI centuries]. Бу исә, үз чиратында, хәзерге татар әдәби телен тагын да камилләштерүгә, тел нормаларын саклауга этәргеч булып тора.

Шулай итеп, тиңдәш кисәкләр озак вакытлар дәвамында өйрәнелеп килеп, нәтиҗәләр билгеле бер калыпка салынган дияргә мөмкин. Синтаксис белән бәйле фәнни хезмәтләрдә, югары уку йорты һәм гомуми белем бирү оешмалары өчен язылган дәреслекләрдә аңлатма бер үк, тиңдәш кисәкләрне бәйләп килә торган чаралар да бәхәс

тудырмый. Иң мөһиме: хәзерге көндә әлеге чаралар тиңдәш кисәкләр белән берлектә нәкъ менә функциональ аспектта тикшерелә.

**Әдәбият**


*Алпаров Г.* Шәкли нигездә татар грамматикасы. Казан, 1926. 164 б.

*Атнагулов С., Алпаров Г.* Грамматика. Синтаксис: Урта мәктәпләре өчен дәреслек. Казан, 1934. 142 б.

*Галләмов Ф. Г.* Тиңдәш кисәкләрнең һәм гомумиләштерүче сүзләрнең синтаксик вазыйфалары // Милли мәдәният. Казан. 2003. Б. 41–46.

Гамәли тел сабаклары. Казан, 1925. 99 б.

*Зәкиев М. З.* Татар синтаксисы: Югары уку йортлары өчен д-лек. Казан: Мәгариф, 2005. 399 б.

*Зәкиев М. З.* Хәзерге татар әдәби теле: Синтаксис. Казан: КДУ нәшр., 1958. 244 б.

*Ибраһимов Г.* Татар нәхүе. Казан: «Өмет» нәшр., 1919. 52 б.

*Ибраһимов С. М.* Синтаксик синонимнар. Казан: КДУ нәшр., 1989. 150 б.

*Корбангалиев М., Бәдигъ Х.* Ана теле нәхүе. Казан: «Миллият» нәшр., 1919. 100 б.

*Максуди Һ.* Төрки нәхүе. Казан: Харитонов нәшр., 1910. 50 б.

Татар грамматикасы. Өч томда. Т. III. М.: Инсан, Казан: Фикер, 1999. 512 б.

*Хангилдин В. Н.* Татар теле грамматикасы (Морфология һәм синтаксис). Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. 642 б.

*Хәкимҗанов Ф. С., Шәкүрова М. М.* Хәзерге татар теле: Пунктуация. Казан: ТДГИ, 2003. 168 б.

*Яруллин Ф. Г.* Күңел яктысы. Шигырьләр, поэма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 384 б.

*Закиев М. З.* Синтаксический строй татарского языка. Казань: Изд-во КГУ, 1963. 464 с.

*Иванов М.* Татарская грамматика. Казань: Типогр. импер. Казанского ун-та, 1842. 342 с.

*Махмудов М.* Практическое руководство к изучению татарского языка. Казань: Изд-во И. Дубровина, 1857. 255 с.

*Мирсиапова Л. Р.* Однородные члены и обобщающие слова в современном татарском литературном языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2010. 20 с.

*Насыйри К.* Краткая татарская грамматика, изложенная в примерах. Казань, 1860. 79 с.

*Хальфин И.* Азбука и грамматика татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов. Казань: Изд-во КГУ, 1809. 107 с.

*Fattahova R. F., Sagdieva R. K., Aydarova S. H., Giniyatullina L. M.* On the origin, phonetic variants, semantic and stylistic peculiarities of the use of the affix-lar in the Turkic languages // Man in India. 2016. № 96 (10). Pp. 3529–3539.

*Husnutdinov D. H., Yusupova Z. F., Shakurova M. M., Yusupov A. F., Mirzagitov R. H.* Practical aspect of comparative research on the material of the Russian and Tatar Languages: XIX–XXI centuries // Journal of Language and Literature. 2016. № 7 (2). Pp. 191–194.

*Husnutdinov, Damir H.; Sagdieva, Ramilya K.* Using computer technologies in teaching process // Turkish online journal of design art and communication. № 6. P. 2369–2375.

*Nurieva F.* Sh. Literary Language of the Golden Horde: Norms and Variations. Life Science Journal, 2014. № 10 (11). Pp. 713–717.

*Yusupov R. A., Aydarova S. H., Sagdieva R. K., Harisova, G. F.* Improving efficiency of teaching the Tatar language to a foreign audience // International Education Studies. 2015. № 8 (5). Pp. 158–164.


# ИЗ ИСТОРИИ ИЗУЧЕНИЯ ОДНОРОДНЫХ СИНТАКСИЧЕСКИХ КОНСТРУКЦИЙ В ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ


**Рамиля Камилевна Сагдиева,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
ramsag777@rambler.ru.



В статье рассматриваются однородные синтаксические конструкции: раскрывается в динамике история их изучения в первых грамматиках и современных научных работах. Обращается внимание на способы и средства связи в этих конструкциях, их роль в стилистике. Выявлена роль однородных сочетаний или предложений в структуре поэтических предложений, их функционально-стилистическая функция.



**Ключевые слова:** однородные члены, члены предложения, средства связи, интонация, союз, смысл, ряд.